Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

26 март, 2020 ел № 257

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин тарафыннан 2018 елга тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләрен карау турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 пунктының 4.5 пунктчасына һәм «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 8 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшергәннән соң, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллинга керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр бирү өлешендә коррупциягә каршы законнар таләпләрен бозган өчен кисәтү рәвешендә дисциплинар җәза кулланырга.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллинга коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә законнар таләпләрен бозуларны булдырмаска тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты идарәсенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиягә йөкләргә.
5. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

СОВЕТ
ПЕСТРЕЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов